**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«17» 02 2025 ел Яр Чаллы ш. № 280

«ТР Тукай муниципаль районы «Мэлэкэс урта белем бирү мәктәбе» тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында» 2024 елның 19 нояберендәге 5187 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы 20 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 январендәге 4 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетның 2024 елның 19 ноябрендәге 5187 номерлы карары белән расланган ТР Тукай муниципаль районы « Мэлэкэс урта белем бирү мәктәбе » муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына 1 кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. ТР Тукай муниципаль районы « Мэлэкэс урта белем бирү мәктәбе » муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев

Муниципаль район Башкарма комитетының 2025 елның «17» 02 280 номерлы карарына 1 кушымта

2025 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мәләкәс урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ буенча түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бер тәрбияләнүчегә бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Дошколенок» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

ТР Тукай муниципаль районы «Мәләкәс урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ директоры ______________ И.Н. Кузнецова

«Бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчесе урынбасары ______________ Р.Р. Йосыпова

ТР Тукай муниципаль районы «Мәләкәс урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәяләр прейскурантына кушымта

1. **«Дошколенок»** - баланың гомуми үсешенә юнәлдерелгән, аның ярдәмендә башлангыч сыйныфларда предметларны уңышлы өйрәнү өчен ныклы нигез булдырыла. Программа балаларны мәктәпкәчә һәм башлангыч белем бирү арасында дәвамчанлыкны тормышка ашыра торган мәктәптә укытуга әзерли.

Программаның максаты - мәктәпкәчә яшьтәге балаларны яңа белем бирү шартларына уңышлы җайлаштыру һәм бер белем бирү баскычыннан икенчесенә гуманлы (уңайлы) күчү шартларын тудыру.

Әлеге хезмәт 6 яшьтән 7 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы 48,4 кв.м., балалар саны - 7.

ТР Тукай муниципаль районы «Мәләкәс урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ директоры ________________ И.Н. Кузнецова